| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2019 Казан шәһәре № 5-90/тэ

«Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте күрсәтә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2020-2022 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» ҖЧҖ) тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2020-2022 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның дәвамлы чорына билгеләнә торган дәвамлы җайга салу параметрларын билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 02.12.2019
№ 5-90/тэ карарына 1 нче кушымта

# «Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» ҖЧЖ тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2020-2022 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» ҖЧЖ | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | - | 455,29 |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | - | 486,00 |
| | | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | - | 472,82 |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | - | 482,79 |
| | | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | - | 482,79 |
| | | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | - | 505,54 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.12.2019 № 5-90/тэ карарына 2 нче кушымта

Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2020-2022 елларга җайга салуның дәвамлы чорына билгеләнә торган дәвамлы җайга салу параметрлары

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | җылылык челтәренең матди сыйфатламасына карата сарыфлар күләме | технологик сарыфлар |
| | | | мең сум | % | Гкал/м$^2$ | Гкал |
| | Казан шәһәре | | | | | |
| 1 | «Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» ҖЧҖ | 2020 | 3802,97 | 1 | 4,3 | 2859,0 |
| | | 2021 | Х | 1 | 4,3 | 2859,0 |
| | | 2022 | Х | 1 | 4,3 | 2859,0 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге